# Капка төбе

Резеда Шамсуллина



Күпме серләр ишеткән ул,
Күпме гашыйклар күргән,
Күпме бирелгән вәгъдәгә,
Ул гына шаһит булган.

Капка төбе сандык кебек,
Җыйган бит хәтирәләр.
Авылларның капка төбе -
Туплаучыдыр хәбәрләр.

Әнә, ак яулыклы әби,
Күз дә алмый урам башыннан,
Газиз балаларын көтеп,
Капка төбенә чыккан.

Гөрли монда иртән-иртүк
Ялга кайткан сабыйлар.
Уеннарны куеп читкә,
Бер кыз саклый бәбкәләр.

Ә кич җиткәч, капка төбе -
Гел әңгәмә үзәге:
Күрше-күләм хәл белешә,
Эч бушата кайбере.

Төннәр буе ике гашыйк,
Капка төбеннән китми,
Хисләр дулкынында йөзеп,
Таң атканын да сизми.

Заманалар үзгәрде шул,
Капка төбендә тынлык.
Халык хәзер сирәк кайта,
Шәһәрдә күреп шатлык.

Кайтыйк без авылларга,
Рәхәтләнеп кич утырыйк,
Капка төбен ятим итми,
Хәтирәләрне барлыйк.